# КАРАР

от 22 ноября 2022 г. №1

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авы җирлегенең Бурсык-Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 22.11.2022 елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авылы җирлегендә Бурсык-Елга авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан) тыш, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала 2023 елда үзара салым кертүгә 700 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Бурсык-Елга авылының 1 Май урамы буенча юлга вак таш түшәү , проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, түләү килешенгү буенча;
- Бурсык-Елга авылындагы юлларны кардан чистарту проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, түләү килешенгү буенча.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 39.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 39 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кәркәүч авыл җирлегенең Бурсык-Елга авылы гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: «2023 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Бурсык-Елга авылында теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада белем алучы 1 төркем инвалидлардан, укучы һәм студентлардан (курсантлардан) тыш, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар

юлламасы белән теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә килешеп торасызмы:

- Бурсык-Елга авылының 1 Май урамы буенча юлга вак таш түшәү , проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, түләү килешенгү буенча;
- Бурсык-Елга авылындагы юлларны кардан чистарту проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, түләү килешенгү буенча.

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Зәйнетдинов